РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 июль 2024ел Буа шәһәре № 1-64

АМС-1 муниципаль милек объектын түләүсез файдалану шартнамәсе буенча тапшыру турында

«Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең 2024 елның 17 маендагы 02/1332 номерлы мөрәҗәгатен карап һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 296, 298, 689 – 701 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәтне түләүсез файдалану шартнамәсе буенча «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенә тапшырырга.
2. «ТР Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә (алга таба – Палата) билгеләнгән тәртиптә түләүсез файдалану шартнамәсен төзергә.
3. Әлеге карар кабул ителгән көннән законлы көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф. Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Советының 2024 елның 24 июлендәге
1-64 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Түләүсез файдалануга тапшырыла торган объект турында белешмәләр**

| № | Исеме | Урнашкан урыны |
|---|---|---|
| 1 | АМС-1 күчемсез мөлкәте (автоматик метеорология станциясе) | ТР, Буа районы, Ырынгы авыл җирлеге |